Татарстан Республикасы
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2006 елның 12 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 19 июлендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993 № 6-7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, №10 (8); 2003, № 5; 2005, № 7-8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Ветеринария эше өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче белгечләр Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органында теркәлергә тиеш.

Ветеринария эше өлкәсендәге белгечләр үз һөнәри эшчәнлекләрендә ветеринария законнарына таяналар һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендә вәкаләтле органына буйсыналар.»;

2) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. **Ветеринария эше өлкәсендә Татарстан Республикасы вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы территориясендә федераль чараларны гамәлгә ашыруда катнашу;

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның авыруларын кисәтү һәм бетерү буенча чаралар үткәрүне һәм хайваннарны дәвалауны оештыру;

Россия Федерациясе карамагына кертелгән мәсьәләләрдән тыш, халыкны кеше һәм хайваннар өчен гомуми булган авырулардан яклау;

ветеринария эше өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче белгечләрне теркәү;

ветеринария эше өлкәсендәге белгечләр эшчәнлегенә контроль;

Россия Федерациясе карамагына кертелгән мәсьәләләрдән тыш, ветеринария эше өлкәсендәге башка мәсьәләләрне хәл итү.

2. Татарстан Республикасы Законы белән җирле үзидарә органнарына ветеринария эше өлкәсендә законнар нигезендә республика карамагына керә торган аерым дәүләт вәкаләтләре бирелергә мөмкин.»;

3) 6 статьяның 2 пунктында «аккредитацияләнгән» сүзен «теркәлгән» сүзенә алмаштырырга;

4) 20 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20 статья. **Ветеринария-санитария экспертизасы**

Терлек продукциясенә, үләннәрдән әзерләнгән терлек азыкларына һәм терлек азыгына өстәмәләргә һәм сәнәгать юлы белән әзерләнмәгән үләнле

продукциягә ветеринария-санитария экспертизасы оештыру һәм үткәрү Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан,Кремль
2006 елның 7 ноябре
№ 67-ТРЗ